КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 6 декабрь г.Казань № 1165

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы милкендәге су объектларыннан файдаланган өчен түләүне исәпләү һәм алу кагыйдәләрен раслау турында» 2009 ел, 8 гыйнвар, 1 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы милкендәге су объектларыннан файдаланган өчен түләүне исәпләү һәм алу кагыйдәләрен раслау турында» 2009 ел, гыйнвар, 1 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 26 декабрь, 938 нче; 2012 ел, 30 июль, 646 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «2006 елның 3 июнендәге 74-ФЗ номерлы» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы милкендәге җир өстендәге су объектларыннан файдаланган өчен түләүне исәпләү һәм алу кагыйдәләрендә:

беренче абзацны төшереп калдырырга;

7 пунктның «а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) су объектларыннан яки аларның өлешләреннән су ресурсларын алуны гамәлгә ашыручы түләүчеләр өчен – түләү чорында алынган су ресурслары күләме (абонентларга тапшыру өчен аларның алынган күләмен кертеп);»;

9 һәм 10 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Түләү чоры өчен түләнергә тиешле түләү күләмен исәпләү судан файдаланучылар тарафыннан, түләү чоры тәмамланганннан соң, тиешле түләү чорының

түләү базасы турындагы мәгълүматлар нигезендә судан файдалану шартнамәсенең шартлары буенча башкарыла.

10. Түләү базасы түбәндәгечә исәпләп чыгарыла:

су объектыннан яки аның өлешеннән су ресурсларының су үлчәү приборлары күрсәткечләренә нигезләнеп билгеләнә, судан файдалануны беренчел исәпкә алу журналында чагылдырыла торган, фактта алынган күләме. Су үлчәү приборлары булмаган очракта, алынган су күләме эш вакытыннан һәм техник чаралар җитештерүчәнлегеннән чыгып билгеләнә. Алынган су күләмен эш вакытыннан һәм техник чаралар җитештерүчәнлегеннән чыгып билгеләп булмаган очракта, алынган су күләме су куллану нормаларыннан чыгып яки судан файдалану шартнамәсендә билгеләнгән шартлар һәм тәртип нигезендә башка ысуллар белән билгеләнә;

су объектының яки аның өлешенең бирелгән акваториясе мәйданы.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин